

Сугышлар беркайчан да булмасын иде. Горләп туйлар узсын, сабыйлар тусын, барысы да әтиле-әниле vссеннәр! Жирдә матурлык яшәсен! Бары матурлык кына доньяны афәттән саклый. Шуна kvрә доньяда яшәvче барлык кешенен бер теләге бар – туган илдә тынычлык булсын!
Шулай, Мордовиянен һәрбер татар авылында да 2019 елнын 9 маенда Боек Ватан сугышынын 74 еллыгына багышланган тантаналы митинглар узды. Хәтта Рузаевка районындагы Верхний Урледим - Югары Орләдем бvген кечкенә генә булып калган авылында да.      Авыл халкы һәм якын тирәдәге ун-унбиш кешелек Тvбән Орләдем белән Яку-Яковщина торак пунктларында барлыгы 90га якын кеше яшәсә дә, анда «Yлемсез полк» акциясе узды. Палаевка - Орләдем авыл жирлеге башлыгы Рахмуков Рифат Рәфик улын аерым билгеләп vтәсе килә; ансыз тантаналы чара vтә алмас иде.
Сугыш, сугыш... кемнәрнен язмышына кагылмаган да, кемнәрнен башларына кайгы, kvз яше, хәсрәт китермәгән ул. Югары Орләдем очен дә сугыш бик зур зыян китерә. Tvбән һәм Югары Орләдемнән Боек Ватан сугышы кырларында 160 кеше батырларча вафат булганнар. Якташларыбызнын 52се генә исән яки яраланып туган якларына кайткан. Сугыш халыкнын яртысыннан артыгын тартып алган! Боек Ватан сугышында һәлак булган якташларыбыз турында хәтер - урамнарыбыз исемендә, истәлек китабына һәрберсенен исеме кертелгән һәм аларнын уллары, кызлары, оныклары, оныкчыклары kvнелендә мәнгегә саклаyачак. Шулай, «Yлемсез полк» ак-циясендә 11 кеше катнашты. Бик аз сан булуга карамастан, Боек Ватан сугышында һәлак булучыларнын истәлеге жирле халык kvнелендә яши. Әйтеп китәргә кирәк; сугыш кагылмаган гаилә юк бу авылларда. 74 ел элек безнен бабайларыбыз һәм аларнын әтиләре Боек Жинv яуладылар,



[illegible]